Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы
Миңлебай авыл җирлеге башкарма комитеты
КАРАРЫ

25 июль 2022 ел № 9

Әлмәт муниципаль районы Миңлебай авылы башкарма комитетының 2022 елның 6 апрелендәге 6 номерлы «Белешмә (өземтә) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында»гы карарына үзгәрешләр кертү турында

Муниципаль хокукый актны гамәлдәге законнарга туры китерү сәбәпле, хокукый мониторинг нәтиҗәләре буенча

Миңлебай авыл җирлеге башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Әлмәт муниципаль районы Миңлебай авылы башкарма комитетының 2022 елның 6 апрелендәге 6 номерлы «Белешмә (өземтә) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында»гы карарына түбәндәге үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә:

1.1. kararга 1 нче кушымтада:

2.5. бүлеге 2.5.1 пунктындагы 5,6 пунктчаларын төшереп калдырырга;

1.2. 2.6. бүлеге 2.6.1 пунктына түбәндәге эчтәлекле 4 пунктчаны өстәргә:

«4) индивидуаль торак йортка хокук билгели торган документлар (әгәр милек хокукы Бердәм дәүләт күчемсез мөлкәт реестрында теркәлмәгән булса)".

2. Әлеге карарны Миңлебай ав., Ш.Бикчурин ур., 50 йорт, Миңлебай ст., Шоссе ур., 20а йорт территориясендә урнашкан махсус стендларда игълан итәргә, шулай ук «Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталы» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Әлмәт муниципаль районы сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылганнан соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Миңлебай авылы башкарма
комитеты җитәкчесе И.М.Рәхимов